وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№1 (170). 4 гыинвар 2013 / 22-сәфәр-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Ислам мәгарифендә – инновацион технологияләр ▷2◁



Мөхәммәд Морад Рәмзи – имам Рабbaниның "Мактубат"ын гарәпчәгә тәрҗемә итүче ▷3◁



Зиратта, кабер янында Коръән уку рөхсәт ителәме? ▷4◁

# ИБРАҺИМ ДУДАРОВНЫҢ ФАҖИГАЛЕ ҮЛЕМЕ УҢАЕННАН

***Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!***

Ибраһим Дударовның туганнары һәм якыннарының, шулай ук барлык Төньяк Осетия мөселманнарының тирән кайгысын уртаклашабыз. Өммәтебез өчен рухи юлбашчыларның берсе булган кардәшебезнең үлеме - зур фаҗига. Татарстанлылар да Алания мөселманнары белән бергә сыкрану хисләре кичерә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) үзенең бер вәгазендә болай дигән: "Кешеләр олы гамәлләре өчен дә, кечкенә гамәлләре өчен дә җавап тотачаклар". Беркем дә гөнаһлары өчен җәзадан азат ителмәячәк, Аллаһ - иң гадел хаким.

Татарстан мөселманнары күпләрнең рухи остазы булган Ибраһим Дударов өчен дога кыла.

Чынлыкта, без барыбыз да Аллаһы Тәгаләнеке һәм барыбыз да Аңа кире әйләнеп кайтачакбыз.

**Үзәкләшкән дини оешма -<br>Татарстан мөселманнары Дииния нәзарәте рәисе,<br>мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**



# ВАКЫТЫГЫЗНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!

**Бөек тәкъва иясе әл-Басри: *"Ий Адәм балалары, син - ул сиңа бирелгән көннәр. Көн үтеп киткән саен, синең дә бер өлешең үтеп китеп бара"*, - дигән.**



Кешенең бар булганнары арасында иң кыйммәтлесе - аның үз карамагында булган вакыты. Шуңа да карамастан, күпләребезнең үз вакытларына игътибарсыз караган кебек башка бер әйбере дә юк. Тәкъдим сорауны тудыра, диләр. Күңел ачу индустриясе ничек үсә барганына карап фикер йөрткәндә, вакытны исраф итүнең никадәр дәрәҗәдә таралыш алган гамәл икәнен күз алдына китерергә мөмкин.

Миллионлаган кешеләр бүгенге көндә асылда бары тик бер продукцияне - вакытны "үтерү" чараларын булдыру өстендә эшләү һәм аларны төзү белән генә мәшгульләр. Кино, телевидение, комарлы уеннар, шулар исәбеннән компьютер уеннары - болар барысы да безнең иң төп, кыйммәтле ресурсны - вакытыбызны юкка чыгару кораллары.

Әгәр дә кисәк кенә тәнебездән көн саен аның бер кисәген кисеп алганнары ачыкланса, без үзебезне ничек хис итәрбез, нинди халәттә булырбыз икән? Башта кулларыбыз, аннан аякларыбыз, аннан тәнебезнең башка өлешләре әкренләп юкка чыгып барганын күзәтеп, без ни хис итә алырбыз икән? Һичшиксез, андый хәл безнең һәрберебезне чиксез өметсезлеккә алып барыр иде. Ә вакытны югалту исә тән әгъзаларыбызны югалтудан күпкә куркынычрак. Әгәр дә без хәтта кайбер әгъзаларыбызны - кул-аякларыбызны югалтсак та, әле бик күп нәрсә эшләргә сәләтлебез.

Тәнебездә җаныбыз бар вакытта, әле без Аллаһны искә төшерә, аңа хезмәт итә алабыз. Ул гына да түгел, әгәр дә сабырлык күрсәтсәк, тәнебезнең югалткан ул өлешләре өчен Хисап көнендә әҗерен дә алырга мөмкинбез. Ә югалткан көнебезне исә без беркайчан да кире кайтара алмаячакбыз. Монысы әле бәланең яртысы гына, чөнки Хисап көнендә исраф ителгән вакытыбыз өчен җавап тотарга туры киләчәк.

Иблиснең безгә каршы кулланган иң тәэсирле чарасы шул: ул безгә "яхшы гамәлләр кылыр өчен алда әле вакыт күп, эшләргә өлгерми калган гамәлләребезне без теләсә кайсы вакытта эшләргә өлгерербез әле" дигән уйны башыбызга сеңдерергә тырыша. Көнкүреш ыгы-зыгысында үтеп барган тормышыбызда без кайчак кисәк кенә "уянып" китәбез дә, боларның барысы да без бу дөньяга килгәч эшләргә тиешле әйберләр түгел икәнлеген, тиз генә нәрсәне дә булса үзгәртергә кирәк икәнен аңлый башлыйбыз.

Ләкин икенче бер мизгелдә үк башыбызга бүтән уй да килә: ашыгудан мәгънә юк, бу эшләрне соңгарак калдырып торырга да була, янәсе. Менә шул уй Иблис коткысы була да инде һәм еш кына безнең күпләребез, шул коткыга би-

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ӘЛМӘТ ШӘКЕРТЛӘРЕ ҖИҢҮ БЕЛӘН КАЙТТЫ**

**29 декабрь көнне Казан шәһәрендә мөселман яшьләре арасында ирекле көрәш буенча бәйге булып узды.** Әлеге чарада төрле шәһәрләрдән килгән көрәшчеләр - шул исәптән, Р.Фәхреддин ис. Әлмәт мәдрәсәсеннән биш шәкерт катнашты. Төрле үлчәү авырлыкларында Әлмәт шәкертләре: Исмәгыйль Зарипов - I урын, Закир Сәгыйтов һәм Марсель Гиздатуллин - III урынга лаек булды.

**РОССИЯ ЗАКОННАРЫ АЕК ЯШӘҮ РӘВЕШЕ ӨЧЕН КӨРӘШӘ**

**2013 елның беренче гыйнварыннан "Этил спирты, алкоголь һәм спирт кергән продукция житештерү һәм аның әйләнешен дәүләт тарафыннан көйләү һәм алкоголь эчемлекләр куллануны чикләү турындагы" Федераль законга кертелгән төзәтмәләр гамәлгә керде.**

Төзәтмәләрдән күренгәнчә, төнге сәгать унбердән (23.00) алып иртәнге сигезгә (8.00) кадәр, Татарстанда исә төнге уннан (22.00) - иртәнге унга (10.00) кадәр сыра һәм башка спиртлы эчемлекләр сату тыелачак.

Киосклар кебек стационар булмаган сәүдә нокталарында сыра сату шулай ук тыела.

*www.islam-today.ru*

**УНИВЕРСИАДА АЛДЫННАН РАДИКАЛЬ АГЫМНАРГА КАРШЫ КӨРӘШ КӨЧӘЙТЕЛӘ**

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Әсгать Сәфәров быел - 2013 елда узачак Универсиада вакытында, куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен, радикаль ислам агымнарына каршы көрәшне көчәйтүнең мөһим булуын билгеләп үтте.**

"Республикада соңгы арада булган вакыйгалар радикаль ислам агымнарына, шул идеологияне таратучыларга комплекслы рәвештә каршы торырга кирәклекне раслады", - диде Ә.Сәфәров.

Аның сүзләренә караганда, радикаль агымнарга бары тик толерантлык идеологиясе һәм дини түземлелек белән генә каршы торып була.

Премьер-министр урынбасары искәртеп узганча, куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен 904 миллион сум акча бүлеп биреләчәк.

*www.islam-today.ru*

**"КОЛ ШӘРИФ" МӘЧЕТЕ ГЫЙНВАР АХЫРЫНДА АЧЫЛАЧАК**

**2012 елның 26 декабрендә "Казан Кремле" музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева журналистлар белән очрашты һәм 2012 елда башкарылган эшләргә нәтиҗәләр ясады.**

Очрашу барышында шулай ук Кол Шәриф мәчете турында да сүз чыкты. Зилә Вәлиева хәбәр иткәнчә, мәчет 2013 елның гыйнварында ачылачак. "Мәчеттә ремонт эшләре 7 ел буена үткәрелмәде, намаз бүлмәсендә бик салкын иде, хәзерге вакытта температура режимын көйли ала торган махсус җайланма куелды һәм "Һәркемгә уңайлы мохит" программасы кысаларында инвалидлар өчен күтәрелү баскычлары булдырылды", - диде ул.

*www.dumrt.ru*

# ИМАМГА ИЯРҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

**Һәр мөселман фәкать Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның илчесенә (сгв) генә буйсынырга тиеш. Пәйгамбәребезгә (сгв) буйсыну - аның безгә Аллаһы Тәгаләнең боерыкларын аңлатуы сәбәпле мәҗбүр ителә. Буйсынуда Аллаһы Тәгаләдән дә лаеклырак зат юк. Әмма гади кешегә Аллаһның нәрсә теләгәнен һәм Аның нәрсәдән риза булганын Аның белән турыдан-туры сөйләшмичә белеп булмаганлыгы ачык күренә. Шулай ук Аллаһның Илчесенә (сгв) турыдан-туры мөрәҗәгать итеп аңардан Аллаһның боерыкларын белү дә мөмкин эш түгел. Шулай булгач, Аллаһка һәм Аның Илчесенә (сгв) буйсыну өчен Аллаһның Китабына һәм Аның Илчесенең (сгв) Сөннәтләренә мөрәҗәгать итүдән башка юл юк.**

Бүгенге көндә Коръән белән Сөннәтнең шәригать кануннары белән ачык расланган һәм ышанычлы чыганаклар белән дәлилләнгән кайбер боерулары бар, алар турында бернинди шик тә, фикер каршылыгы да юк (мәсәлән, зинаның тыелуы, биш вакыт намазның, уразаның, зәкятнең һәм хаҗның мәҗбүри булуы). Һәр кеше бу боеруларны үзлегеннән белергә мөмкин, шуңа күрә дә бу мәсьәләләрдә иҗтиһад (Коръәннән һәм Сөннәттән ачык әйтелмәгән шәригать хөкемнәрен чыгару өчен бар көчеңне, тырышлыгыңны кую) кылуның яисә кемгә дә булса иярүнең хаҗәте юк.

Әмма Коръәндә һәм Сөннәттә икенче төрле боерулар да бар һәм аларны аңлауда төрле кыенлыклар туа, чөнки бер үк мәсьәләдә ике төрле күрсәтмә булырга мөмкин һәм алар икесе дә Коръәндә һәм хәдисләрдә булган ышанычлы чыганаклар белән расланалар. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә:

وَ الْمُطَلَّقَاتُ يَتَرَبَّصْنَ بِأَنْفُسِهِنَّ ثَلٰثَةَ قُرُوْءٍ

"Талак кылынган хатыннар икенче иргә барганчы өч күрем вакыты көтәрләр" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 228 нче аяте).

Монда قُرُوْءٍ сүзе сүзлектә ике мәгънәгә ия: беренчесе - күрем килү, икенчесе - аңардан чистарыну. Монда без кайсы мәгънәне алырга тиеш дигән сорау туа.

Яисә, мисал өчен, бер хәдистә әйтелгән:

لا صلوة لمن لم يقرأ بفاتحة الكتاب

"Фатиха" сүрәсе укымаган кешенең намазы юк". Бу хәдис беренче карашка имамга да, аның артында торучыга да, аерым укучыга да "Фатиха" сүрәсен укуның мәҗбүри булуын аңлата кебек. Әмма икенче бер хәдистә әйтелә:

من كان له إمام فقرأءة الامام له قراءة

"Имамга оеп намаз укучының Коръән укуы булып имамның укуы тора".

Бу хәдистән исә имамга оеп укучының бер нәрсә дә укырга тиеш түгел икәнлеге күренә.

Бу хәдисләрдәге ачык күренгән аермалыклардан саклануның ике юлы бар. Беренчесе - әүвәлге хәдисне нигез итеп алырга һәм аның белән гамәл кылырга, чөнки икенче хәдистә Коръән уку дигәндә "Фатиха" сүрәсе түгел, бәлки "Фатиха" сүрәсеннән соң килә торган сүрәләр күздә тотыла. Икенчесе - икенче хәдисне нигез итеп алырга һәм аның белән гамәл кылырга, чөнки беренче хәдистә "Фатиха" сүрәсен укуны боеру фәкать имамга гына һәм аерым укучыга гына кагыла, имамга оеп укучыга кагылмый. Бу очракта нишләргә?

Коръәнне һәм хәдисләрне аңлатканда шуның кебек сораулар еш туа. Безнең алдыбызда мондый кыенлыклардан чыгу юлы фәкать икәү генә булырга мөмкин: үзебезгә кайсы да булса бер якны сайлап алу һәм үзебезнең белемгә һәм акылга таянып гамәл кылу яисә (аның урынына) зур белемгә ия булган элекке галимнәрнең ничек эш йөртүләренә карарга, үзебез ныграк ышана торган галимнең һәм мөҗтәһиднең фикеренә таянып гамәл кылырга.

Соңгы юл "тәкълид" (кемгә дә булса иярү) сүзе белән билгеләнә. Әгәр төптән уйлап карасак, алда әйтелгәннәрдән беренче юлның куркынычрак һәм анда адашу мөмкинлегенең күбрәк икәнлегендә шикләнергә урын юк. Безнең белемебезнең һәм тәкъвалыгыбызның ислам дине тарала башлауның беренче чорларында яшәгән мөселманнарның белеме һәм тәкъвалыгы белән һич кенә дә чагыштырып булмаслык дәрәҗәдә икәнлеген фәкать гафилләр генә кире кагарга мөмкин. Беренчедән, имам-мөҗтәһидләр Аллаһның Илчесенә (сгв) якынрак чорда яшәгәннәр, шуңа күрә дә аларга Коръәнне һәм Сөннәтне, шулай ук Коръәннең иңү шартларын аңлау безгә караганда җиңелрәк булган. Икенчедән, безнең белемебезне һәм аңыбызны Аллаһы Тәгалә аларны нигъмәтләгән белем һәм аң дәрәҗәләре белән берничек тә чагыштырып булмый. Өченчедән, Аллаһы Тәгалә һәрвакыт гөнаһ эшләргә әзер булганнарга хаклыкны һәм Коръән белән хәдисләрне аңлауны ачык кылмый. Коръәннең һәм хәдисләрнең мәгънәләрен дөрес аңлау өчен белем генә җитми, бәлки аеруча ныклы тәкъвалыкка ия булырга кирәк. Әгәр без үзебезнең тәкъвалык белән имам-мөҗтәһидләрнең тәкъвалыкларын чагыштырып карасак, җир белән күк арасындагы аерманы күрербез.

Ислам шәригате принципларын урнаштыручы галимнәр тәкълидне түбәндәгечә билгеләгәннәр:

العمل بقول إمام مجتهد من غير مطالبة دليل

"Имам-мөҗтәһидләрнең сүзләренә нигезләнеп, дәлил таләп итмичә гамәл кылырга". Кайбер кешеләр шушы аңлатмаларга таянып, дәлилсез әйтелгән сүзләргә иярү һәм аларны берсүзсез хак дип кабул итүне ширек була дип әйтә башлады. Әмма, алда әйтелгәнчә, тәкълид турында аңлатуны карасак, бу тәнкыйть үзеннән-үзе юкка чыга. Мөҗтәһид шәригать урнаштырмый, бәлки аны аңлата гына. Ышанычлы чыганаклар белән расланучы Коръән һәм Сөннәтнең ачык боеруларындагы мәсьәләләрдә безнең ниндидер бер имамга иярмәвебез моны исбат итүче дәлил булып тора. Без Коръәнне һәм хәдисләрне аңлатуда туган шикләргә һәм кыенлыкларга кагылган мәсьәләләрдә генә яисә Коръәндә һәм хәдисләрдә бер үк сорау буенча төрле күрсәтмәләр булганда гына мөҗтәһидләргә мөрәҗәгать итәбез.

Тәкълидне аңлатканда "дәлил таләп итмичә гамәл кылу" дигән сүздән мөҗтәһиднең үзенә буйсынырга кирәк дигән ялгыш нәтиҗә ясарга кирәк түгел. Чынлыкта, мөҗтәһиднең Коръәннән һәм хәдисләрдән алынган көчле дәлилләре булуына ышануыбыз сәбәпле генә аңа мөрәҗәгать итәбез. Һәм фәкать аның дәлилләренең дөреслеген тикшерерлек иҗтиһад кылырга безнең көчебез тиешле дәрәҗәдә булмавы сәбәпле генә без аңардан дәлил таләп итмибез. Шулай итеп, мөҗтәһиднең сүзләре белән гамәл кылу өчен ул китергән дәлилләрне белү мәҗбүри түгел, чөнки кайбер мәсьәләләрдә без аларны аңласак та, күпләрендә без аларны аңламыйбыз.

**"Исламда мәзһәб мәсьәләсе"**
**китабыннан алынды, Чаллы, Ак мәчет**

# ИСЛАМ МӘГАРИФЕНДӘ – ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

**Конфессиональ мәгариф яңа социаль-мәдәни, сәяси һәм икътисади шартларда алып барыла. Илебезнең иҗтимагый аңында рухи-әхлакый тәрбия проблемасы иң алгы сафларның берсенә чыкты.**



Дингә килүчеләрнең артуы, дини мәгариф учреждениеләренең күпләп ачылуы, Россия халыкларында гасырлар буена урнашкан дини-мәдәни традицияләрнең яңадан торгызылуы, иң беренче чиратта, заман таләпләренә җавап бирүче югары квалификацияле кадрлар булдыруны һәм җәмгыятьнең хәзерге вакыттагы үсешенә туры килә торган конфессиональ юнәлешле мәгариф системасын булдыруны күз алдында тота. Хәзерге вакытта конфессиональ мәгарифне торгызу процессы зур авырлыклар белән бара: системалылык, мәгариф үсеше берлеге, бердәм концептуаль карашлар, укыту-методик базалар юк (бу, бигрәк тә, ислам мәгарифе системасына кагыла). Ислам нигезләрен һәм инкыйлабка кадәрге Россиядә конфессиональ мәгарифнең үсеше тарихын тирәнтен (фәнни) өйрәнү белән бергә, хәзерге Россия шартларында ислам мәгарифе үсеше үзенчәлекләрен өйрәнү буенча тикшерүләр дә юк диярлек. Мәгариф практикасы мәгариф үсешенең концептуаль нигезләрен билгеләүне, мәгариф стандартлары төзүне, үсешнең яңа модельләрен барлыкка китерүне, инновацион мәгариф технологияләрен эзләүне таләп итә.

Мәгариф системасында инновацион процесслар "яңарту, камилләштерү, булганын яхшырту" буларак карала.

Дини мәгарифтә инновацияләр, новаторлык мөмкинме соң? Инновацияләр кертү зарури, чөнки, бу очракта, без мәгариф системасы турында сүз алып барабыз. Шуңа да, педагогик практикада кулланыла торган яңа технологияләр мөселман мәгарифе системасында да кулланылырга тиеш. Аны булдырмаган очракта без дөньядан артта калачакбыз. Күптән түгел генә Согуд Гарәбстанында Ислам дөньясы университетлары федерациясе киңәшмә үткәрде. Анда мөселман мәгарифе системасының бер Россиядә генә түгел, ә бәлки бар дөньяда да яңа инновацион мәгариф технологияләре куллану буенча, кызганыч, Көнбатыш Европа системасыннан калышу мәсьәләсе тикшерелде. Шул ук вакытта, дистанцион укыту формасы, уку йортлары системасын тәшкил итә торган виртуаль ислам университеты төзү идеясе дә каралды.

Ислам мәгарифе системасы күп еллар буена эшләми торган иде, шуңа да хәзер бу системаны торгызган вакытта катып калган ниндидер формаларны "сындыру" зарурлыгы юк. Шуңа күрә яңа мәгариф процессын оештырган вакытта мәгарифнең заманча технологияләренә таянырга кирәк. Шул ук вакытта, классик мөселман мәгарифе турында сүз йөрткәндә, элеккеге традицияләр дә юкка чыкмаска тиеш. Бу очракта, яңа технологияләр белән укытуның классик ысулларын бергә бәйләп алып бару булырга тиеш. Бу динне эмоциональ кабул итү ягыннан да, белем алу ягыннан да бик мөһим.

Хәзерге ислам мәгарифе үсешенең нигезе булып җәдитчеләрнең эшчәнлеге торырга тиеш. Аны без ислам мәгарифе үсеше тарихындагы инновацион процесс буларак карыйбыз.

Бу хәрәкәтнең инновацион проектлары укыту методикасын үзгәртүдән башланып киткән. Аннан соң ул чылбыр буенча мәгарифнең башка өлкәләрендә дә үзгәрешләр кичергән.

Җәдитчелек, урнашып алган традицияләрдән китеп, андагы әһәмиятле бар өлешләрне үз эченә алып, ул тарихи чорда җәмгыять алдына килеп баскан мәсьәләләрне чишү өстендә эшләп, ислам мәгарифе системасын яңартуга ирешә. XIX йөз ахыры - XX йөз башында дөньяви һәм мөселман мәгарифенең уңышлы интеграциясе нәтиҗәсендә кайбер уку йортлары Европа дәрәҗәсендәге иң яхшы уку йортлары булып таныла.

Бу процесслар нәкъ менә ул вакыттагы Россия чынбарлыгыннан башланып китәләр дә. Башта Г.Курсави (1776-1812), аннан чак кына соңрак Ш.Мәрҗани (1818-1889), Р.Фәхреддин (1859-1936) һ. б. күтәреп чыккан проблемалар үсеш ала, аларның идеяләре бар мөселман Көнчыгышы өчен актуаль булып чыга. XIX йөз ахыры - XX йөз башында мөселман реформаторлыгы бар мөселман цивилизациясенең дә казанышына әйләнә.

Тормышның хәзерге спецификасы дини (ислам) уку йортлары алдында башка мәсьәләләр дә куя, ләкин бу инновацион хәрәкәтнең күп аспектларын Россия җәмгыяте үсешенең икътисади, социаль-мәдәни һәм рухи-әхлакый принципларындагы үзгәрешләрне исәпкә алып, хәзерге шартларда торгызырга туры киләчәк.

Диннең үз асылында инновацияләргә юл куймавы - гомуми билгеле әйбер, тик, шулай да, мәгариф процессын оештыруда яңача якын килүләр таләп ителә. Шулай итеп, мәгариф процессын оештыру - ул мәгариф учреждениесенең структур бүлекчәләрен, оештыру-штат структурасын төзү; хезмәт күрсәтүнең тиешле (норматив) документациясен эшләү; төп мәгариф программаларны әзерләү; укыту процессының бар баскычларында да планлаштыруны булдыру; кадрлар белән һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү; укытуның бар баскычлары өчен дә укыту, укыту-методик һәм фәнни әдәбият әзерләү.

Шулай итеп, дини мәгарифтәге инновацияләр дигәндә, без дини уку йортының мәгариф процессына, дини мәгарифнең үсешенә ярдәм итә торган, аның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирә торган заманча технологияләр, модельләр, ысуллар эшләп чыгаруны, аларга пробацияләр эшләүне, таратуны һәм кертүне аңлыйбыз.

Дини мәгарифне оештыруда нинди инновацияләр кулланылырга мөмкин соң?

1. Илебездәге бар дини (ислам) уку йортларын да үз эченә алган бердәм мәгариф системасын булдыру.

2. Дини һәм дөньяви дисциплиналарның оптималь чагыштырмасы булган, яңартылган программалар, уку планнары булдыру.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Мөхәммәд Морад Рәмзи - имам Раббанины "Мактубат"ын гарәпчәгә тәрҗемә итүче

**Бик күпләрнең имам Раббани язган "Мактубат" китабы турында ишеткәне бардыр. Ләкин бик азыбыз гына бу хезмәт белән таныша алуыбыз өчен кемгә рәхмәт әйтәсен белә...**



Бөтен хикмәт тә шунда: "Мактубат" иң әүвәл фарсы телендә язылган. Ә аны гарәп теленә Мөхәммәд Морад Рәмзи әл-Минзәләви (аның исеме Морадаллаһ бине Баһадиршаһ Абдаллаһ бине Гаделшаһ Рәмзи буларак та билгеле) тәрҗемә иткән.

Мөхәммәд Морад Рәмзи әл-Минзәләви - танылган татар галиме, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе. Ул 1855 елның 25 декабрендә (башка чыганаклар буенча 1854 елның 10 октябрендә) Уфа губернасындагы Минзәлә өязенең Әлмәт авылында (хәзер Татарстанның Сарман районына керә) дөньяга килгән.

Башта үзенең әнисендә белем алган, аннан соң, сигез яше тулгач, Әлмәт мәдрәсәсенә йөргән. 1869 елда Казанга килгән, укуын берара Мәрҗәни мәдрәсәсендә (хәзерге вакытта бу бинада Казан ислам көллияте урнашкан) дәвам иткәннән соң, белемен тагын да тирәнәйтү нияте белән Бохарага юл тота. Юл уңае белән Троицкига туктала һәм ике елын Мөхәммәджан мулла мәдрәсәсендә үткәрә. 1874 елның язында Бохарага килә, бер елдан соң Ташкентка күченә. Бу вакытларда ул казакъ һәм кыргызлар арасында мөгаллимлек итә. 1877 елда яңадан Бохарага килә, аннан соң Ташкентка килеп, анда ике ел белем ала.

1878 елда М.Рәмзи хаҗ кылырга чыгып китә. Җиддәдә һәм шул ук елның октябрендә Мәккәдә була. Хаҗ кылганнан соң, ул Мәдинәгә юнәлә, башта андагы "Әмин-ага", бераздан "Шифа", ә аннан соң "Мөхәммәдия" мәдрәсәләрендә укый. Ул, шул ук вакытта, нәкышбәндия тарикате остазы Мөхәммәд Мәзһәрнең мөриде булып китә һәм аннан иҗазәт (рухи остаз булырга рөхсәт) ала.

Соңыннан Мөхәммәд Морад укуын Мәккәдә Габделхәмид әд-Дагстани шәехтә дәвам иттерә. Аның вафатыннан соң, 1884 елда ул элеккеге остазының дәвамчысы Мөхәммәд Салих әз-Завави шәехнең дәресләрен тыңлый. Әз-Завави исә 1885 елда Мәккәгә күченеп килә һәм 1886 елда аны үзенең Мәккәдәге варисы итеп билгели. Шәехнең тәкъдиме белән ул Әхмәд Сирхиндинең (1564-1624) "Мактубат" китабын һәм "Рашәхәт гәйн әл-Хәят"тән ("Мәңгелек тормыш чыганагы тамчылары") алып, Вәгыйзь Кашифиның (1463-1531) нәкышбәндия тарикате әгъзаларында киң таралган агиографик хезмәтен фарсычадан гарәпчәгә тәрҗемә итә башлый.

Кайбер чыганакларга караганда, Мәдинәдә Мөхәммәд Морад Габдерәшид Ибраһим һәм Семипалатинсклы Габделхак Йосыф белән очраша. 1895 елда ул өйләнә, әмма тугыз баласының дүртесе кече яшьтә үк вафат булалар. 1899 елда хаҗ кылырга килгән кардәше Йосыф Дебердиев аңа яңа йорт сатып алып бирә. 1902, 1904, 1907, 1909, 1914 нче елларда М.Морад туган якларына кайтып килә. Үзенең билгеле "Талфик әл-Әхбар вә талких әл-асар фи вәкаи Казан вә Болгар вә мөлек әт-татар" ("Казан, Болгар һәм татар хакимнәре турында хәбәрләр вә мәгълүматлар") китабын ул 1892 елда яза башлый һәм 1907 елда тәмамлый. Бу хезмәт гарәп телендә язылган. Ләкин китап цензура аша узмый, бары тик Н.Катанов һәм Гайнетдин Әхмәров ярдәме белән генә ул 1908 елда Оренбургта 2 том булып нәшер ителә. Бу вакытта аны бастыру өчен шәех Зәйнулла Рәсүли үзенең матди ярдәмен күрсәтә. Бөек галим Мөхәммәд Морад Рәмзи 1934 елның 2 апрелендә Кытайның төньяк-көнбатышында урнашкан Чугучак шәһәрендә вафат була.

**Чыганак: www.huzur.ru**

# ВАКЫТЫГЫЗНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!

***(Дәвамы. Башы 1 нче биттә.)***

релеп, мөһим адым ясауны, ниндидер билгеле бер датага, мәсәлән, Яңа елга яки ураза ае башлану вакытына калдырып тора. Шулай итеп, Иблис үз максатына ирешә, без үзебез өчен иң мөһим булган эшләребезне елдан-ел калдырып киләбез, аннан соң инде картлык та килеп җитә яки - тагын да яманрагы - гомереңнең соңгы сәгате сугып куюы да бар.

Һәр яңа көннең безгә: ***"Ий Адәм балалары, менә ул мин - яңа көн, сезнең бу көнге гамәлләрегезнең шаһиты. Мине яхшы эшләр өчен файдаланып калыгыз, мин киткәнмен икән, сезгә Кыямәт көне җиткәнче кире кайтачагым юк"***, - дип мөрәҗәгать иткәнен без онытып җибәрәбез.

Хәтта инде без, беркайчан да вакытны сузарга кирәкмәгәнен тәмам төшенеп, ни өчен бу дөньяга килүебезне "тормышка ашыра" башласак та тормышыбызның иң яхшы, иң зур кыйммәткә ия булган чакларын, ягъни яшьлегебез көннәрен югалткан булуыбызны аңлый башлыйбыз.

Шундый бер хәдисне китерәләр. Пәйгамбәребез (сгв) әйткән: ***"Ул Кыямәт көнендә дүрт сорауга: аның тормышы һәм ул аны ничек итеп үткәргәне турында; аның яшьлек еллары һәм ул аны ничек файдаланганы турында; аның байлыгы һәм ул байлыкны ничек итеп тапканы, ничек сарыф иткәне турында; аның гыйлеме һәм ул гыйлемнәрне файдаланып ниләр кыла алуы турында җавап бирми торып, бер генә бәндәнең дә ул көнне бер аягы да кыймылдамаячак"***.

Бу хәдис дәлилләгәнчә, Мөхәммәд (сгв) безнең яшьлек елларыбыз, аны ничек итеп үткәрүебез турында аерым сораячакларын искәртә. Ә бу исә, яшьлек көннәренә аерым игътибар итүнең никадәр мөһим икәнлегенә дәлил.

Икенче бер билгеле хәдистә исә башкалар эсселектән һәм сусаудан газап чиккән вакытта Кыямәт көне күләгәсендә хозурлана торган кешеләрнең җиде төре күрсәтелгән. Яшьлек гомерен Аллаһка хезмәт итүгә багышлаганнар да шулар арасында бар. Болар - Иблис вәсвәсәсенә бирешмичә, Аллаһка хезмәт итүне гомер ахырына калдырмаган затлар. Алар тормышларының иң яхшы көннәре өчен иң күркәм гамәлләр кылганнар һәм Аллаһы Тәгалә аларны башкалардан өстен күреп, сайлап алган.

Шулай итеп, яхшы гамәлләр кылуны картлыкка калдырып тору турындагы уй башка килү белән, бу уйның кайдан, кем тарафыннан килүенә төшенү лазем. Һәм дә бу - уйга ияреп гамәл кылган вакытта ниләр югалтачагыгыз һәм нәрсәгә ия булачагыгыз турындагы коткы уйларга да кагыла.

## Эшләргә мөмкин булган эшләрнең күбесен эшләргә кирәк түгел,

### яки Ничек итеп вакыттан дөрес файдаланырга?

Ә бит вакытның мөһим икәнлеген аңлаган кешеләр күпме булган?! Алар үзләренең һәр минут-секундының кадерен белгәннәр, тик шулай да тормышларын кирәкмәгән максатларга файдаланганнар! Бар гомерен суалчаннарны өйрәнүгә багышлаган бер галимнән: "Ни өчен сез бар гомерегез буена суалчаннар белән шөгыльләнәсез?" - дип сораганнар. Ә ул: "Суалчан нинди озын, ә тормыш бик кыска", - дип җавап биргән.

Әлбәттә, кеше үз тормышын шундый максатлар өчен дә сарыф итәргә мөмкин. Ләкин ул үзенең бу дөньяга ни рәвешле килүе, ә аннан соң, үзенең гомере беткәннән соң кая барачагы турындагы сорауларга җавап табып, шуны аңлар өчен бер генә сәгать вакыт та таба алмый.

Безне Аллаһы Тәгалә яраткан. Кеше өчен нәрсә әйбәт һәм тормышны нәрсәгә багышларга кирәк икәнен Аннан башка беркем дә яхшырак белә алмый. Аеруча мөһим булган бу сорауга җавап табу өчен, әйдәгез, Аллаһның Китабына - Коръәни-Кәримгә мөрәҗәгать итик.

Аллаһы Тәгалә әйтә: ***"Мин җеннәрне һәм кешеләрне табынудан башка булган эшләр өчен яратмадым"***.

Аллаһка гыйбадәт кылу - кеше омтылырга тиешле бердәнбер максат. Табынудан тыш булган бар гамәлләр дә, буш кына түгел, ә бәлки зыянлы да. Дин белән аз таныш булган кешеләргә үз тормышының максаты итеп Аллаһка табынуны сайлап алган кешеләр гомерләрен интегүдә һәм газапта үткәрүче ниндидер бер дәрвишләр һәм аскетлар булып та күренергә мөмкин. Чынбарлыкта исә Аллаһка табынуны үз максаты итеп алган кеше, дөньявилыкның колы булган башка кешеләр белән чагыштырып караганда, хәтта бу дөньяда да күпкә бәхетлерәк була.

**Беренчедән**, аңа дөнья рәхәтлекләреннән баш тартып тору өчен зарурлык юк, ул бу дөньядагы бар байлыкларга ия булып та Аллаһның тәкъва бер колы булырга мөмкин. Моның өчен Сөләйман пәйгамбәр мисалын искә төшерү дә җитәр. Аннан тыш, безнең карашка дөньяви булып күренгән гади бер гамәлләре өчен дә, ул ахирәттә әҗерен алырга мөмкин.

Хәдисләр буенча, үзен, үз гаиләсен тоту һәм башкаларга ярдәм итү йөзеннән дөнья байлыкларын табучы да Аллаһ юлыннан бара. Бар хикмәт тә шунда: бу байлыкларны нинди ният белән үзеңнеке итүдә. Һәм дә Кыямәт көнендә безгә ниятләребез буенча хөкем чыгарылачак.

**Икенчедән**, әгәр дә ул бәндә бик каты фәкыйрьлеккә төшсә, шуның өстенә авыру һәм бәла-казалар боз яңгыры кебек явуга да карамастан, ул кеше, барыбер, бар белгәне шушы фани дөнья чикләреннән ары китә алмаганнардан күпкә бәхетлерәк булачак. Сезнең ниндидер билгеле бер максат өчен бары тик бер көн өчен генә, ниндидер бер ярышта җиңүче булып чыгасы көн өчен генә - ай арты ай, ел арты ел көн-төн тырышкан, тир түккән спортчыларны күргәнегез бардыр. Аларны бәхетсез дип кем әйтә ала? Бары тик бер уйдан, ул бу ярышларда җиңүче булып чыгачагы уена карап та ул бәхетле. Ниндидер бер ярышта җиңүче булу Аллаһның Җәннәте белән чагыштырырлыкмы соң? Әгәр кем дә булса бар авырлыкларга түзеп, табынуда иҗтиһад күрсәтә икән, ул кешене, аның бу иҗтиһады өчен алыначак бүләк, берни белән дә, хәтта бар бу дөнья, андагы бар байлыклар белән дә чагыштырып булмаган бер вакытта, - бәхетсез дип әйтеп буламы соң?

Бер хәдистә әйтелгән: ***"Иманлы кешенең хәле таң калырлык! Чынлап та, аның бар халәте дә аңа игелек; һәм бу иманлы кешеләрдән башка бирәүгә дә бирелмәгән. Әгәр дә ул аны шатландыра торган нигә дә булса очрый икән, ул аның өчен Аллаһка шөкер итә, һәм бу аңа яхшылык булып китә. Әгәр дә инде ул ниндидер бәла-казага тарыса, ул, бу очракта да сабырлык күрсәтә һәм бу бәла-каза да аның өчен яхшылыкка әйләнә"***.

**Өченчедән**, Аллаһы Тәгалә, табынуда иҗтиһад күрсәткән колларының күңелләренә үзенең шифалы нурларын сибә. Күңелләренә шундый нурлар сирпелгән кеше, бар төннәрне дә Аллаһка табынып үткәреп, зур хозурлык тоя. Билгеле тәкъва иясе Әбу Сөләйман әд-Дарани: ***"Төнлә Аллаһка табынган кешеләр, башкалар күңел ачу чараларында алганга караганда, күпкә зуррак ләззәт кичерә"***, - дип әйткән.

Икенче бер тәкъва иясе: ***"Әгәр дә хакимнәр безнең ни халәттә икәнебезне белсәләр, алар бу халәт өчен кулларына корал алып сугышка чыгарлар иде"***, - дигән.

Җаннары үле булганнар тәкъваларның бу сүзләрен аңлый алмаячак. Тик аннан гына чынбарлык үзгәрми. Ә чынбарлык исә гел үзгәрешсез: Аллаһка табыну юлын сайлаган кеше ике дөньяда да чиксез бәхетле була.

## Башта - гыйлем, аннан соң гына гамәлләр

Аллаһка хезмәт итү юлын сайлаган кешегә, иң беренче эш итеп, зур белемнәргә ия булырга кирәк. Гыйлем кулланып эшләнгән аз гына гамәлләрдән дә гаять зур файда алырга мөмкин. Ә гыйлем кермичә кылынган бик күп сандагы гамәлләрдән файда ул кадәр үк булмас.

Белем алу зур тырышлык сорый. Һәм дә бу юлга баскан кеше, иң беренче чиратта, үз вакытын контрольдә тотарга һәм аны бушка сарыф итмәү ягын карарга тиеш. Бары тик шул юл белән генә бөек галимнәр үз максатларына ирешкәннәр.

Бик күп китаплар язып чыгарган (ә аның бер китабы гына да 800 биттән тора!) бине Акил әйткән: ***"Минем өчен үз гомеремнең бер генә сәгатен дә бушка сарыф итү мөмкин эш түгел иде. Минем телем фәннәрне тикшерү һәм кабатлау, ә күзләрем - укуга булган сәләтләрен югалткач та, мин фикер йөртергә тотындым; ятып ял итеп алган араларымда алга таба нәрсә язачагым турында уйлый һәм бу җәһәттән бер фикергә килми торып, яткан җиремнән тормый торган идем. Инде менә хәзер сиксән яшь тулгач та, мин егерме яшьтә булган чагыма караганда үземдә күбрәк гыйлемгә сусау һәм белем эстәүгә омтылуда күбрәк хаҗәтлек сизәм"***.

Ул, шул ук вакытта, азык кабул итүгә киткән вакыт китаплар язуга һәм укуга тотылсын өчен, азыкның да азрак чәйнәп ашый торганын сайлап алырга кирәк, дип әйтә торган булган.

Әбу Йосыфның улы вафат булгач, үз остазы Әбу Хәнифәнең дәресләрен калдырмас өчен, ул аны юууны һәм җирләүне күршеләренең берсенә тапшырган булган.

Әбу Йосыфның укучысы Ибраһим бине Җараһ авырган вакытында аңа килгәч, ул аны аңын җуйган хәлендә очраткан. Әбу Йосыф аңына килгәч: "Ий Ибраһим, синең фәлән-фәлән мәсьәлә буенча фикерең ничек?" - дип аннан сораган. Ибраһим моңа таң калган. "Сез үзегез шундый авыр хәлдә, ә үзегез шул турыда сорыйсыз", - дигән. Ә Әбу Йосыф аның бу соравын: "Минем ни хәлдә булуымның әһәмияте юк, ә менә тикшерелгән бу мәсьәлә аркасында кем дә булса котылып калырга мөмкин", - дип җаваплаган һәм шәригать мәсьәләләрен тикшерүне дәвам иткән.

Әгәр берәр кеше безгә килеп акча сорый икән (ул безгә ошап бетмәсә), без ул кешене тиз генә борып чыгарырга һәм аның белән башка очрашмаска тырышабыз. Ә безнең үзебездә булган иң кадерле әйберебезне - вакытыбызны кирәкмәгән юк-бар сөйләшүләр белән бездән тартып алалар икән, безнең бик азларыбыз гына бу турыда кайгыра башлый.

Бер кеше Әмир бине Кайска мөрәҗәгать итеп, аңа: ***"Туктап тор әле, минем синең белән сөйләшәсем килә", - дигән. Тегесе аңа: "Башта Кояшны тукта-***

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# Зиратта, кабер янында Коръән уку рөхсәт ителәме?

**Әлеге мәсьәләгә аңлатма алу йөзеннән без Татарстанның көньяк төбәге казые, Чистай районы имам-мөхтәсибе Алмаз хәзрәт ШӘРИФУЛЛИНга мөрәҗәгать иттек.**

Изге Коръән мөэмин-мөселманнарга күрсәтмә, шифа, рәхим-шәфкать һәм җитәкчелек буларак иңдерелгән. Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): "Кем Коръән укый, аның мәгънәсен аңлапмы-аңламыйчамы, һәрбер укылган хәреф өчен - ун савап, ә Коръәнне уку үзе үк гыйбадәт", - булыр дигән. Ә аны мәрхүмнәргә Аллаһның рәхим-шәфкатен һәм Коръән шифасын җиткерү өчен укырга буламы соң? Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) яки сәхабәләрнең бу турыда ни дә булса әйткән сүзләре яки гамәлләре бармы? Әллә инде бу гамәлләр, кайберләрнең әйтүе буенча, уйлап чыгарылганмы?

Хәнәфиләр "кабердә һәм башка урыннарда мәрхүмнәр рухына Коръән уку дөрес, кирәкле гамәл" дип исәплиләр, ә мәрхүм рухына юнәлтелгән бу гамәлнең савабы аңа барып ирешә дип раслыйлар. Хәнәфи мәзһәбе буенча язылган фикъһе китапларында әлеге мәсьәләдә болай дип әйтелә: "Әгәр дә кеше намаз, зәкят, ураза, хаж, Коръән уку кебек гыйбадәтләр кылып, моны башкаларга багышлый икән, ул нинди ният белән генә моны эшләсә дә, болай багышлап гыйбадәт кылу - хак гамәл һәм ул кемгә багышлап кылынса да, ул кешегә моның савабы барып ирешәчәк. Ул кеше исән булса да, мәрхүм булса да моның зур әһәмияте юк". Моңа дәлил итеп Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үз өммәте өчен корбан китерүе һәм мәрхүмнәр исеменнән хаҗ кылырга һәм сәдака таратырга, ә мәрхүмнәрнең кабере өстендә "Йәсин" һәм "Ихлас" сүрәләре укырга мөмкин булуы турындагы хәдисләрне китерәләр. Факиһ һәм хәдисләр белгече Айнидан (855/1451 елны вафат) башлап, бине Абидинга (1252/1836 елны вафат) кадәрге бар хәнәфи мәзһәбе факиһлары да шундый фикердә тора.

Бу мәсьәлә буенча кире, капма-каршы позициядә торган беркем дә юк. Алар арасында беренчеләре дә (мөтәкаддимун) һәм аннан соңгы буындагылары да (мөтәәххирун) бу уңайдан гел бер үк караштa торганнар. Бу галимнәрнең сүзләренә караганда, хәнәфи мәзһәбенең карашы шундый: әгәр дә кеше намаз, ураза, сәдака, хаж, Коръән уку кебек изге гамәлләр кылып, аның савабын мәрхүмнәр рухына багышлый икән, бу гамәлләрнең савабы мәрхүмнәргә барып ирешәчәк.

# ВАКЫТЫГЫЗНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛЕГЕЗ!

*(Ахыры. Башы 1,3 нче битләрдә.)*

***тып тор"***, - дип җавап биргән.

Икенче бер галимнең янында кешеләр озаграк тора башласа: ***"Безгә саубуллашырга вакыт түгелме? Бу кояшның Хакиме, аны, чынлап та, хәрәкәткә китерә, ул хәрәкәт бер мизгелгә генә дә туктап тормый"***, - дип әйтә торган булган.

"Без бу галимнәр кебек үз вакытыбызның һәр мизгелен контрольдә тота, аны кирәкмәгән башка нәрсәгә исраф итми тора да алмыйбыз", - дип кайбер укучыларыбыз каршы чыгарга да мөмкин. Андый шикшөбһәләре булганнарга минем бер яхшы кагыйдә китерәсем килә. Ул болайрак яңгырый: ***"Тулысынча ирешә алмаганның барысыннан да тулысынча ваз кичәргә кирәк түгел"***. Әгәр дә кешеләр шушы кагыйдә буенча эш йөртсәләр, алар бу тормышта бик күп нәрсәгә ирешә алган булыр иде.

Ә кем дә кем көн саен бер генә сәгать вакытын булса да гыйлем туплау өчен җәлеп итә алмый ди әле? Шул бер генә сәгатьне бүлеп тә, без күп әйберләргә ирешә алган булыр идек.

**Беренчедән**, гыйлем туплау өчен сарыф ителгән бу вакыт - Аллаһка табыну өчен киткән вакыт. Шуның өстенә, бу - безнең табынуларга үткәргән вакытыбызның иң яхшысы.

**Икенчедән**, булган белемнәребез аркасында, тышкы яктан дөньяви гамәлләр кебек күренгән эшләребезне дә без Хисап көнендә әҗерен алырга мөмкин булган гамәлләргә әйләндерә алабыз.

**Өченчедән**, белемнәрең булып, белеп кылынган Аллаһка табынуларның кыйммәте күп тапкырлар артык.

Шуңа күрә вакытның зур кыйммәт икәнен аңлаган кеше өчен көн саен берничә минут вакытны булса да белем туплауга юнәлтү зарур.

**Фәһим хәзрәт ӘХМӘТҖАНОВ,**
**Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые,**
**Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе**

# Мәчетләрне төзекләндерү буенча зур эш башкарылды

**Нурлат районының Кәкре Атау авылында үткән район имамнары җыелышы 2012 елга нәтиҗәләр ясауга, киләсе елга планнар коруга багышланды. Узган Коръән елы кысаларында район мәчетләрен төзекләндерү буенча бихисап эшләр башкарылды. Шәһәр үзәгендә төзелеп килүче мәдрәсәдә 900 мең сумлык эшләр үткәрелде.**

- Иске Авылда бер ел дигәндә яңа мәчет торгызылды, киләсе елга Бикүле, Түбән Нурлат авылларында дин йортлары үз ишекләрен ачачак, - диде район мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов үз чыгышында.

Кизләү, Якты Күл, Кәкре Атау авыллары, Шикәрчеләр бистәсе мәчетләрендә колачлы ремонт эшләре үткәрелде. Төзекләндерү буенча зур эшләр башкарылган мәчет имамнарына бу көнне мөхтәсибәтнең Рәхмәт хатлары да бирелде. Сөйләшү барышында киләсе елда юбилейларын билгеләп үтәчәк Колбай Мораса һәм Кәкре Атау авыллары мәчетләре хакында, моннан тыш, зур тарихка ия булган Кизләү авылы мәчетен пансионат итү турында да сүз барды.

Уку-укыту өлкәсендә дә ел уңышлы булды. Апрель аенда мөгаллимнәр арасында укулар оештырылса, балалар арасында район һәм республика күләмендә узган Коръән уку бәйгеләрендә 160 бала катнашкан. 18 бала приз белән бүләкләнгән, 2 бала Төркиядә укуларда булган. Бүгенге көндә ике йөз иллеләп бала дин нигезләрен үзләштерә. 2012 елда җәйге дини лагерьлар 16 авылда оештырылган. "Киләчәктә һәр татар авылында да лагерь оештыруны максат итеп куябыз, - диде Айрат хәзрәт. - "Заречный" сәламәтләндерү лагерендa дин белән кызыксынучы балалар өчен аерым смена оештыру турында сүз алып барабыз. Моннан тыш, мөселман яшьләре арасында спорт секцияләре эшен җайга саласы иде".

Сөйләшү барышында мәчетләрне рәсмиләштерү, хосусыйлаштыру мәсьәләләре дә каралды.

Үзара аралашу рәвешендә барган чарадан имамнар шактый мәгълүмат туплап таралышты, дип хәбәр итә районның "Дуслык" газетасы.



# ИСЛАМ МӘГАРИФЕНДӘ – ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

3. Мәҗбүри бердәм уку дәреслекләре әзерләп бастыру.
4. Методологияне һәм укыту методикаларын эшләү.
5. Бердәм квалификацион таләпләр буенча ислам мәгарифенең бар баскычлары өчен дә мөдәррисләр әзерләү.
6. Күп баскычлы дөньяви мәгариф системасына юнәлеш тоту.

Мондый яңалыклар мәгарифнең эчтәлегендә, оештыру формаларында, аның белән җитәкчелек итүдә, укыту формаларында кулланылырга мөмкин.

Мәскәү ислам университетының көндезге уку бүлеге деканы, педагогика фәннәре кандидаты Гөлфия Юныс кызы Хәбибуллина сүзләренә караганда, хәзерге мөселман мәгарифенең нәтиҗәлелеге түбәндәге оештыру-педагогик шартлар белән билгеләнә:

1) тиешле хокукый, оештыру һәм методик база төзү;
2) тиешле матди тәэмин ителеш булдыру;
3) кадрлар әзерләү; булачак белгечләрнең гомуми фәнни, махсус теоретик һәм практик әзерлекләренең логик бәйләнешен булдыру;
4) укытучыларның компетентлыгы, югары һөнәрилеге һәм методик яктан осталыгы;
5) мәгълүматны һәм хәзерге тормыштан алынган тиңдәш мисалларны җентекләп сайлап алулары;
6) дини мәгарифне мәгълүматлаштыру һәм анык мәгариф технологияләрен актив файдалану;
7) ислам мәгарифенең төрле баскычлары арасында күчеп килүчәнлелекне тәэмин итү;
8) уку йортының һәм бар ислам мәгарифенең бөтен структур бүлекчәләренең дә үзара килешенгән профессиональ эшчәнлекләре;
9) уку-укыту сыйфатын күтәрүдә катнашу һәм чыгарылган белгечләрнең алга таба эшчәнлекләрен күзәтеп бару;
10) Ислам мәгарифенең өстәмә нәтиҗәле системасын төзү.

Хәзерге вакытта мәгариф системасы һәм оештыру мәсьәләләре белән җитәкчелек итү проблемасын чишү өчен Россиянең төрле регионнарында конфессиональ мәгарифнең инновацион үсеш модельләре буларак, университет үзәкләре төзелә.

Бу яңа модель университетлары ислам мәгарифе үсеше үзәкләре булудан бигрәк, җитәкчелек итү, оештыру, координацияләү, методик, диагностик (контроль) функцияләр башкара, яңа типтагы оешмалар - инновацион уку учреждениеләре булып торалар. Шулай итеп, бу уку йортлары сыйфатны планлаштыра, уку процессын оештыра, нәтиҗәләрне контрольдә тота һәм анализлый.

Мәгариф процессының адаптацион механизмнарын һәм сыйфатны яхшырту формаларын эзләү, дини мәгарифтә дөньяви һәм дини компонентларның оптималь чагыштырмасын тикшерү - дини мәгарифтә педагогик инноватика булып тора. Уңышлы яңалыкларның мисалы итеп теологиядә мәгариф буенча дәүләт стандартларын кертүне атарга мөмкин. Шулай итеп, җәмгыять үсешенең яңа шартларына адаптацияләнүдә төрле оештыру-җитәкчелек технологияләрен файдалану инновацион эшчәнлек булып тора.

Ислам мәгарифе үзенчәлекләрен исәпкә алган яңа мәгариф стандартларын, программалар эшләүне шулай ук уңыш дип атау дөрес булыр. Традицион конфессиональ дисциплиналарның эчтәлеген яңа формада ачу - перспектив яңалык.

Нәтиҗә ясап, иң якын киләчәктә шуларны эшләү зарури икәнен билгеләп үтәргә кирәк:

1) Россиядә бердәм ислам мәгарифе киңлеген формалаштыру. Аны формаштырган вакытта уку йортлары һәм Диния нәзарәте турыдан-туры катнашырга тиеш.
2) Дини уку йортларының аттестация, аккредитация һәм финанс мәсьәләләре буенча тыгыз һәм үзара актив бәйләнеш булдыру.
3) "Дөньявилык" төшенчәсен конфессиональ якын килү кысаларында тирәнтенрәк өйрәнү.
4) Дини мәгарифнең баскычлы структурасын үстерү һәм мәдрәсәләр, югары дини уку йортлары арасында тыгыз бәйләнеш булдыру.
5) Җәдит мәгарифе системасында булган традицияләргә тирәнтенрәк тикшерүләр үткәрү һәм аларны хәзерге уку-укыту процессында файдалану.
6) Уку планнарын универсализацияләү һәм оптимизацияләү кысаларында дөньяви һәм дини дисциплиналарның бер-берләренә үзара өстәүчелек принципларын саклау.
7) Мәгариф стандартларын һәм уку планнарын эшләү вакытында комплекслы якын килү.

Һичшиксез, конфессиональ мәгарифтә инновацион эшчәнлек яңа идеяләр туута һәм аларны тормышка ашыруга китерә. Ислам мәгарифенә куелган бу тырышлыклар һәм ясалган үзгәрешләр бернинди шик-шөбһәләрсез мәгариф учреждениеләренең тотрыклы үсешенә һәм төрле мәдәниятләрнең бер-берләренә үтеп керүгә китерәчәк.

**Габдрахман хәзрәт ХӘБИБУЛЛИН,**
**Мамадыш мәдрәсәсе директоры**

«**Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 1 (170) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35384.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 3 гыйнвар көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**